**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты составына вазыйфалар буенча үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеген оештыру һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 21 июлендәге ПУ-668 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты составына вазыйфалар буенча, аны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 15 гыйнвар
№ ПУ-5

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның «15» гыйнварындагы
ПУ-5 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппаратының вазыйфалар буенча составы**

1. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе.
2. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесе, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе урынбасары.
3. «Республика яшьләр, инновация һәм профилактика программалары үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе урынбасары.
4. Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсенең дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире.
5. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге өлкән белгече.

---